**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ**
**СЮНДЮКОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СӨЕНДЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422396 с.Сюндюково, ул.Такташа, 15

422396 Сөендек авылы,Такташурамы, 15

тел. (84373) 5-07-27, факс 5-07-27, e-mail: ssundukovo@mail.ru
ОГРН 1021606557136, ИНН/КПП 1638001663/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24 .10. 2024** **№ 41-1**

## ФИЗИК ЗАТЛАР МӨЛКӘТЕНӘ САЛЫМ ТУРЫНДА

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Сөендек авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының "Сөендек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советының " Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 11.11.2014 ел, №52-1 карарына өстәмәләр кертергә:

1.1. 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 6 пунктча өстәргә:
«Гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган сәүдә һәм административ-эшлекле үзәкләр (комплекслар) буенча 2025-2027 елларның күчеш чорына 1,2 процент, һәм алардагы биналар, 2028 елдан күрсәтелгән биналарда 2 процент ставкасы билгеләнә».

2. Әлеге карар үз көчен 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерә һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Сөендек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**Җитәкче** **Х.А.Измайлов**